ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^1$ статьяның 2 өлешендә:
а) түбәндәге эчтәлекле $10^4$ пункт өстәргә:
«$10^4$) төзелеш өчен рөхсәт алу таләп ителмәгән очракларны билгеләү;»;
б) түбәндәге эчтәлекле $10^5$ пункт өстәргә:
«$10^5$) атмосфера һавасын саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә җирлек, шәһәр округы территорияләрендә атмосфера һавасы пычрану буенча җыелма исәпләүләр үткәрелгән булса, җирлекнең генераль планы проектын, шәһәр округының генераль планы проектын атмосфера һавасын саклау өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән килештерү тәртибен билгеләү;»;

2) 5 статьяның 6 өлешендә «соңга калмыйча» сүзләреннән соң «, ә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 16 статьясындагы $5^1$ һәм $5^2$ өлешләрендә каралган очракларда аны расларга кимендә бер айдан да соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

3) 7 статьяның 7 өлешендә «соңга калмыйча» сүзләреннән соң «, ә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 21 статьясындагы $6^1$ һәм $6^2$ өлешләрендә

каралган очракларда аны расларга кимендә бер айдан да соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

4) 9 статьяда:

а) 2 өлешнең 1 пунктында «, йә җирле әһәмияттәге мондый объектларга ихтыяҗ булу турында, аларның төп характеристикаларын һәм урнашу урынын күрсәтмичә, белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлешнең 3 пунктында түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Генераль планда функциональ зоналары билгеләнми торган территорияләр күздә тотылырга мөмкин.»;

5) 10 статьяның 8 өлешендә «аларны» сүзен «аны» сүзенә алмаштырырга, «соңга калмыйча» сүзләреннән соң «, ә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясындагы $7^1$ һәм $7^2$ өлешләрендә каралган очракларда аны расларга кимендә бер айдан да соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

6) 14 статьяның $3^2$ өлешендәге 6 пунктында «Татарстан» сүзен «Озак вакытлы чорга Татарстан» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Җирлекләрнең генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, үзгәрешләр кертү җирлекләрнең генераль планнарына, шәһәр округларының генераль планнарына үзгәрешләр кертү өчен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 13 ноябрь
№ 65-ТРЗ